**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 14 гыйнвар | № 7

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетың «2016 елга Татарстан Республикасы карамагындагы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 2 октябрь, 731 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетың «2016 елга Татарстан Республикасы карамагындагы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 2 октябрь, 731 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2016 елга Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»;

1 пунктның икенче абзацында «карамагындагы» сүзеннән соң «кадет мәктәбе» махсус исемле» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның өченче абзацында «карамагындагы» сүзеннән соң «кадет мәктәбе» махсус исемле» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы карамагындагы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар»;

«Кадетлар интернат мәктәбе» юлында «Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум» графасында «120» саннарын «120 126» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы карамагындагы гомуми белем бирү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү күләменә төзәтү коэффициентлары исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы карамагындагы «кадет мәктәбе» махсус исемле гомуми белем бирү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү күләменә төзәтү коэффициентлары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\7.docx